РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Башлык
Азнакай муниципаль районының Уразай
авыл җирлеге
муниципаль районы

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Азнакай муниципаль районы
Уразай авылы җирлеге
башлыгы

ул.Н.Бадертдинова ур., 35 йорт, Уразай
авылы,
Азнакай муниципаль районы, 423303

Н.Бадертдинов урамы, 35,Уразай авылы
Азнакай муниципаль районы
423303

Тел./факс(885592)43-5-55; E-mail:Uraz.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» март 2022 ел №1

Уразай авылы гражданнары җыенының 2021 елның 17 декабрендәге 1 нче, 2 нче номерлы карарларына үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карау буенча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең Уразай торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Уразай авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Уразай авылы гражданнары җыенының 2021 елның 17 декабрендәге 1 нче, 2 нче номерлы карарларына үзгәрешләр кертү турындагы мәсьәләне карау буенча 2022 елныц 11 мартына 09 сәг.00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез, Себер язвасы белән авырган маллар күмелгән үләт базын ремонтлау турындагы мәсьәләне, 2021 елның 17 декабрендәге Уразай авылы гражданнар җыенының 1 нче, 2 нче карарларыннан төшереп калдырырга ризамы?

« РИЗА» "КАРШЫ"

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча : http//aznakayevo.tatarstan.ru һәм Уразай авылы, Н.Бәдертдинов, 35 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

УРАЗАЕВСКИЙ СОВЕТ СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Башлык: А.М.Шәрифуллина